*Исправления не допускаются!*

**Межрегиональная предметная олимпиада Казанского федерального университета**
**по предмету «Татарский язык»**
**2012-2013 учебный год**

**9 класс**

**Шифр_____** **Итоговой балл ____ ______**подпись предс. жюри

**I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез. – Найдите в каждом тесте один правильный ответ. (25 баллов)**

1. Татар телендә ничә сузык аваз бар?
   а) 9; ә) 12; б) 13; в) 6.
   2. Кое сүзендә е хәрефе ничек укыла?
   а) [й ы]; ә) [й е]; б) [й о]; в) [й ө].
3. борыны — [ б о р н о ]. Бу — нинди күренеш?
   а) ассимиляция; ә) диссимиляция; б) редукция күренеше; в) элизия күренеше.
4. ***Унбиш*** сүзенең язылышы нинди орфографик принципка нигезләнгән
   а) фонетик; ә) морфологик; б) тарихи; в) график.
5. **Комбинатор үзгәрешләр** дип нәрсә атала?
   а) авазларның сүздәге урынына бәйле үзгәреш; ә) авазларның бер-берсенә тәэсире нәтиҗәсендә барлыкка килгән үзгәреш; б) сүзләрне һәм морфемаларны төзүче, аларны бер-берсеннән аеру өчен хезмәт итүче иң кечкенә аваз берәмлеге;в) һава дулкыннарының тирбәнеше.
6. **Бәкәй, ихата, тутырык** кебек сүзләре кайсы өлкәгә карый?
   а) диалекталь лексикага; ә) гади сөйләм лексикасына; б) гомумкулланыш лексикасына; в) һөнәрчелек лексикасына.
7. **“**Үзегезгә булсын бүлмәгез,
   Юлларымны ләкин бүлмәгез” (Ә.Әтнабаев) җөмләсендә ***бүлмәгез*** **сүзе**
   а) омоформа; ә) омограф; б) омофон; в) саф лексик омоним булып килә.
8. **Ономастика фәненең өйрәнү обьекты нәрсә?**
   а) җөмләләрнең төзелеше; ә) кеше исемнәре; б) авыл, шәһәр, торак пункт исемнәре; в) ялгызлык исемнәр.
9. ***Физра, пед, мед, телик, матем*** **кебек сүзләр нинди сүзләргә керә?**
   а) арго сүзләр; ә) тарихи сүзләр; б) архаизмнар; в) жаргон сүзләр.
10. Сүзнең төп вазифасы нидән гыйбарәт?
    а) бәйли; ә) аера; б) тасвирлый; в) атый.
11. **Балыкчылар** сүзендә кушымчаларның ялгану тәртибен күрсәтегез:
    а) тамыр+сүз ясагыч кушымча+модальлек кушымчасы; ә) тамыр+модальлек кушымчасы+сүз ясагыч кушымча; б) тамыр+сүз ясагыч+бәйләгеч; в) тамыр+бәйләгеч кушымча+сүз ясагыч кушымча.
12. **Кушымчалау юлы** белән нинди сүзләр ясалалар?
    а) кыскартылма сүзләр; ә) кушма һәм парлы, тезмә сүзләр; б) ясалма сүзләр; в) бары тик парлы сүзләр генә.
13. ***Ташбака, төнбоек, ата-ана, кара чәчле, кием-салым*** сүзләре ничек ясалганнар?
    а) ясагыч кушымча белән; ә) сүзләр кушылу юлы белән; б) фонетик юл белән; в) күчү юлы белән.
14. Сүз ясагыч кушымча ярдәмендә генә ясалган сүзләрне күрсәтегез:
    а) тугандаш, шәһәрчек, алтынчы, дуслык, илем; ә) аша, көчсез, шатлык, уйчан, русча; б) сыерчык, ташчы, салмак, сусыл, укучы; в) ачкыч, килде, алсу, туганны, балалар.
15. ***Энә карагы, бал корты, кош теле, нарат гөмбәсе*** исемнәре нинди юл белән ясалганнар?
    а) ике сүзне тезү юлы белән — тезмә исемнәр; ә) ике исем янәшә килгән, ләкин уртак мәгънә белдерми; б) болар — гади сүзтезмәләр; в) мөстәкыйль мәгънәләрен югалтып, кушылып ясалган исемнәр.
16. «***Әйткән сүз — аткан ук***» җөмләсендә билгеләнгән фигыльләр кайсы төркемчәгә карыйлар?
    а) билгесез үткән заман хикәя фигыль; ә) хәзерге заман сыйфат фигыль; б) үткән заман сыйфат фигыль; в) исемләшкән сыйфат фигыль.
17. Мәгънәләре ягыннан рәвеш төркемчәләре ничә?
    а) алты; ә) сигез; б) дүрт; в) рәвеш төркемчәләре юк.
18. «***Икенче көнне алар авылга кайттылар***» җөмләсендәге ***икенче*** сүзенә морфологик анализ ясагыз.
    а) икенче — сан, тәртип саны, *көнне* сүзен ачыклый, төрләнмәгән, җөмләдә тәмамлык булып килә; ә) икенче — сан, тәртип саны, *көнне* сүзен ачыклый, төрләнмәгән, җөмләдә аергыч булып килә; б) икенче — микъдар саны, *көнне* сүзен ачыклый, төрләнмәгән, җөмләдә аергыч булып килә; в) икенче — рәвеш, сыйфат рәвеше, *көнне* сүзен ачыклый, төрләнмәгән, җөмләдә аергыч булып килә;
19. Затланышсыз фигыльләрне билгеләгез.

а) сыйфат фигыль, хәл фигыль, исем фигыль, инфинитив; ә) исем фигыль, шарт фигыль, теләк фигыль, хәл фигыль; б) хикәя фигыль, боерык фигыль, шарт фигыль, теләк фигыль; в) сыйфат фигыль, хәл фигыль һәм инфинитив.

20. «***Әлләниләр сизенә күңелем, әллә ниләр уйланам*** (Һ. Такташ)» җөмләсендә ***әллә*** сүзе кайсы төркемгә карый?

а) билгесезлек алмашлыгы; ә) билгеләү алмашлыгы; б) сорау алмашлыгы; в) стилистик төсмерле кисәкчә.

21. **Гөлгенә мәзәк кенә көлеп куйды, чиләге чайкалып, суы түгелде (А.Гыйләҗев) җөмләсе**

а) күп иярченле катлаулы кушма җөмлә; ә) тезем; б) катнаш кушма җөмлә; в) аерымланган хәлле гади җөмлә.

22. «*Аннан бөтен кешеләр күренсен иде: әти дә, бабай да, токтыннар да, Костин абый да, теге токтын апа да, матрос та күренсен иде.* (Г.Гобәй)» дигән җөмләдә «***әти, бабай, токтыннар, Костин абый, токтын апа, матрос***» сүзләре җөмләнең кайсы кисәге булып килгән?

а) ия; ә) тәмамлык; б) хәл; в) аергыч.

23. «*Урмандагы агачлар ямь-яшел яфрак ярды*» җөмләсендә ничә сүзтезмә бар?

а) ике сүзтезмә: *урмандагы агачлар; ямь-яшел яфрак;* ә) өч сүзтезмә: *урмандагы агачлар; ямь-яшел яфрак; агачлар яфрак ярды;* б) бу — җөмлә, җөмлә составында сүзтезмә була алмый; в) өч сүзтезмә: *урмандагы агачлар; ямь-яшел яфрак; яфрак ярды.*

24. Җөмлә төрен билгеләгез: ***Җир чокырсыз булмас, урман киексез булмас*** (Мәкаль).

а) иярчен аергыч җөмләле кушма җөмлә; ә) теркәгечсез тезмә кушма җөмлә; б) бер составлы гади җөмлә; в) аналитик иярченле кушма җөмлә.

25. ***«Туган телебезне сакларга кирәк»*** җөмләсе кайсы төргә карый?

а) бер составлы фигыль җөмлә; ә) бер составлы исем җөмлә; б) тулы җөмлә; в) кушма җөмлә.

**II. Хикәядән соң булган тест биремнәрен үтәгез. – Выполните тестовые задания, приведенные после рассказа. (За каждый правильный ответ** (тест № 1-19 + задание № 20) **(19 балл. + 6 балл.) 25 баллов**

Кызлар һәм малайлар

(1) *Кызлар, сөенешеп, таганга менеп утырдылар.* (2) *Малайлар аларны тирбәтеп җибәрделәр.* (3) *Салмак кына тирбәлгән таганда күзләрне йомып хыялланырга рәхәт.* (4) *Күзләрне йомгач, дөнья серләнә.* (5) *Атынгыч, әкиятләрдәге тылсымлы келәм кебек, сине ерак-еракларга алып китә.* (6) *Йә син, болытлардан да югары күтәрелеп, зәңгәр офыкларны кочасың, йә, кояшка кулларыңны сузып, бөеклегеңне исбатларга телисең.* (7) *Ә кеше үз максатына ирешкән көнне чынлап та бөек була.* (8) *Кызларның бүген дөньялары түгәрәк, бәхетләре бөтен иде.* (9) *Алар туйганчы атындылар, иң усал малайлар да аларны куарга ашыкмады.* (10) *Эшләгән эшләренең нәтиҗәсен һәм кызлар йөзендә балкыган шатлыкны күрү усал малайларны да йомшарткан иде.* (11) *Хәер, кызлар үзләре дә малайларның киң күңеллелегенә шуның белән үк җавап бирергә тырыштылар.* (Ф.Яруллин).

1. Кайсы җөмләдә ирен гармониясенә буйсынган 3 сүз бар?

а) *Кызлар, сөенешеп, таганга менеп утырдылар.* ә) *Йә син, болытлардан да югары күтәрелеп, зәңгәр офыкларны кочасың, йә, кояшка кулларыңны сузып, бөеклегеңне исбатларга телисең.* б) *Ә кеше үз максатына ирешкән көнне чынлап та бөек була.* в) *Эшләгән эшләренең нәтиҗәсен һәм кызлар йөзендә балкыган шатлыкны күрү усал малайларны да йомшарткан иде.*

2. Кайсы җөмләдә 3 ясалма сүз кулланылган?

а) *Атынгыч, әкиятләрдәге тылсымлы келәм кебек, сине ерак-еракларга алып китә.* ә) *Йә син, болытлардан да югары күтәрелеп, зәңгәр офыкларны кочасың, йә, кояшка кулларыңны сузып, бөеклегеңне исбатларга телисең.* б) *Эшләгән эшләренең нәтиҗәсен һәм кызлар йөзендә балкыган шатлыкны күрү усал малайларны да йомшарткан иде.* в) *Хәер, кызлар үзләре дә малайларның киң күңеллелегенә шуның белән үк җавап бирергә тырыштылар.*

3. 3 нче җөмләдәге ***хыялланырга*** сүзе нинди мәгънәле кисәкләрдән тора?

а) тамыр, 3 ясагыч кушымча; ә) тамыр, 2 ясагыч кушымча; б) тамыр, 1 ясагыч һәм 1 модаль кушымча; в) тамыр, 1 ясагыч һәм 1 бәйләгеч кушымча.

4. 10 нчы җөмләдәге сыйфат фигыльләр:

а) *эшләгән*; ә) *эшләгән, балкыган*; б) *эшләгән, балкыган, йомшарткан*; в) сыйфат фигыльләр юк.

5. Кайсы җөмләдә бүлүче теркәгечләр кулланылган?

а) *Салмак кына тирбәлгән таганда күзләрне йомып хыялланырга рәхәт.* ә) *Йә син, болытлардан да югары күтәрелеп, зәңгәр офыкларны кочасың, йә, кояшка кулларыңны сузып, бөеклегеңне исбатларга телисең.* б) *Ә кеше үз максатына ирешкән көнне чынлап та бөек була.* в) *Хәер, кызлар үзләре дә малайларның киң күңеллелегенә шуның белән үк җавап бирергә тырыштылар.*

6. **4 нче төр хәл фигыль формасы** кулланылган җөмләне билгеләгез:

а) *Кызлар, сөенешеп, таганга менеп утырдылар.* ә) *Салмак кына тирбәлгән таганда күзләрне йомып хыялланырга рәхәт.* б) *Күзләрне йомгач, дөнья серләнә.* в) *Алар туйганчы атындылар, иң усал малайлар да да аларны куарга ашыкмады.*

7. Гади җөмләне билгеләгез:

а) *Күзләрне йомгач, дөнья серләнә.* ә) *Йә син, болытлардан да югары күтәрелеп, зәңгәр офыкларны кочасың, йә, кояшка кулларыңны сузып, бөеклегеңне исбатларга телисең.* б) *Кызларның бүген дөньялары түгәрәк, бәхетләре бөтен иде.* в) *Алар туйганчы атындылар, иң усал малайлар да да аларны куарга ашыкмады.*

8. 10 нчы җөмләдә туры тәмамлыклар:

а) *нәтиҗәсен, шатлыкны;* ә) *нәтиҗәсен, шатлыкны, малайларны;*б) *эшләренең, нәтиҗәсен, шатлыкны, малайларны;* в) *эшләренең.*

9. Инкарь җөмләне билгеләгез:

а) *Күзләрне йомгач, дөнья серләнә.* ә) *Ә кеше үз максатына ирешкән көнне чынлап та бөек була.* б) *Кызларның бүген дөньялары түгәрәк, бәхетләре бөтен иде.* в) *Алар туйганчы атындылар, иң усал малайлар да да аларны куарга ашыкмады.*

10. 11 нче җөмләдә өтер ни өчен куелган?

а) тиңдәш кисәкләр санау интонациясе ярдәмендә бәйләнеп килгәннәр;
ә) эндәш сүз җөмләнең башында килгән; б) гомумиләштерүче сүз тиңдәш кисәкләрнең алдыннан килгән; в) кереш сүз җөмләнең башында килгән.

11. **"Күзләрне йомгач, дөнья серләнә"** дигән 4 нче җөмләдә ясалу урыны буенча **й тартыгы**

а) тел алды тартыгы; ә) йоткылык тартыгы; б) ирен-ирен тартыгы; в) тел уртасы тартыгы.

12. **«Кызлар, сөенешеп, таганга менеп утырдылар»** дигән җөмләдә **кызлар** җөмләнең кайсы кисәге булып килгән?

а) эндәш сүз; ә) ия; б) аныклагыч; в) хәл.

13. 1 нче җөмләдә өтер ни өчен куелган?

а) санап китү интонациясе белән килгән; ә) каршы куючы теркәгечләр алдыннан; б) аерымланган рәвеш хәле; в) кереш сүз җөмләнең уртасында килгән.

14. **"Алар туйганчы атындылар, иң усал малайлар да аларны куарга ашыкмады"** дигән җөмләдә ***да*** нәрсә ул?

а) кисәкчә; ә) модаль сүз; б) җыючы теркәгеч; в) бәйлек.

15. **«Малайлар аларны тирбәтеп җибәрделәр»** дигән җөмләдә хәбәрнең төрен билгеләгез:

а) тезмә хәбәр; б) кушма хәбәр; в) гади хәбәр; г) парлы хәбәр.

16. "**Хәер, кызлар үзләре дә малайларның киң күңеллелегенә шуның белән үк җавап бирергә тырыштылар**" дигән җөмләдә **хәер** кереш сүзе

а) сөйләүченең төрле тойгыларын белдерә; ә) тыңлаучыны җәлеп итүне белдерә; б) фикернең дөреслеген белдерә; в) чама белән әйтүне белдерә.

17. «*Малайлар аларны тирбәтеп җибәрделәр*» дигән җөмләдә ничә сүзтезмә бар?

а) ике сүзтезмә: *аларны тирбәтү; аларны тирбәтеп җибәрү;* б) бу — җөмлә, җөмлә составында сүзтезмә була алмый; в) өч сүзтезмә: *аларны тирбәтү; малайлар тирбәтеп җибәрү; аларны тирбәтеп җибәрү;* г) бер сүзтезмә: *аларны тирбәтеп җибәрү.*

18. "**Күзләрне йомгач, дөнья серләнә**" *дигән 4 нче җөмлә*

а) тиңдәш түгел иярүле күп иярченле кушма җөмлә; ә) берничә төр иярүле катлаулы кушма җөмлә; б) аерымланган хәлле хикәя җөмлә; в) иярченле кушма җөмлә.

19. "**Атынгыч, экиятләрдәге тылсымлы келәм кебек, сине ерак-еракларга алып китә**" дигән 5 нче җөмләдә **экиятләрдәге тылсымлы келәм кебек**

а) эпитет була; ә) метафора; б) чагыштыру; в) синоним була.

20. Бирелгән җөмләләрдәге тыныш билгеләренең ни өчен куелуын аңлатыгыз. - Объясните постановку знаков препинания. **(6 баллов).**

(8) *Кызларның бүген дөньялары түгәрәк**,** бәхетләре бөтен иде.* (9) А*лар туйганчы атындылар**,** иң усал малайлар да аларны куарга ашыкмады.*

(11) *Хәер**,** кызлар үзләре дә малайларның киң күңеллелегенә шуның белән үк җавап бирергә тырыштылар.*

**III. Нокталар урынына тиешле сүзләр өстәп языгыз. – Вставьте вместо точек нужные слова. (20 баллов)**

1. Үзара ияртүле бәйләнешкә кергән мөстәкыйль мәгънәле ике яки берничә сүздән торган төзелмә **…** дип атала.
2. Сүзнең бер-бер артлы тамырга ялганып килеп, аңа нинди дә булса мәгънә өсти торган кисәкләре **…** дип атала.
3. Җөмләдә мөстәкыйль мәгънәле һәм аерым сорауга җавап бирә торган сүз **… …** дип атала.
4. Бер телдән икенче телгә кисәкләп — морфемалап тәрҗемә ителгән сүз **…** була.

5. Сөйләүченең чынбарлыкка, сөйләмнең эчтәлегенә төрлечә мөнәсәбәтен белдерә торган сүзләр … **…** дип атала.

6. Үзләре ияреп килгән сүзне бары тик бер генә яктан ачыклый торган иярчен кисәк **… …** дип атала.

7. Санап кителгән тиңдәш кисәкләрнең барысын бергә туплап, гомумиләштереп әйтә торган лексик берәмлекләр **… …** дип атала.

8. Үзара тезү юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән торган кушма җөмлә **…** була.

9. Сөйләм төбәлгән затны, әйберне белдергән сүзләр **…** … дип атала.

10. Баш җөмләгә үзенең хәбәре составында тормый торган чаралар ярдәмендә ияргән җөмлә **… …** дип атала.

**IV. Биремнәрне үтәгез. Выполните задания. (10 баллов)**

*Ком сахрасында ыгы-зыгы басылгач(...) мин дә илкәемә кайтып китәрмен әле* (Т.Әйди).

1. Кушма җөмләнең төрен билгеләгез. - Определите тип сложного предложения. (2 балла)

2. Тыныш билгеләрен куеп, аңлатыгыз. - Поставьте и объясните знаки препинания). (2 балла)

3. *Басылгач* сүзенә морфологик анализ ясагыз. – Сделать морфологический анализ слова "**басылгач**" (2 балла).

4. *Илкәемә* сүзен төзелеше ягыннан тикшерегез. - Разбор слова *илкәемә* по составу (2 балла).

5. *Ыгы-зыгы* сүзенең синонимнарын табыгыз. **–** Найдите синонимы слова "ыгы-зыгы" (суматоха). (2 балла)

**V. Хикәядәге нокталар урынына кирәкле хәрефләрне, кушымчаларны яки сүзләрне языгыз. - Вставьте вместо точек нужные буквы, окончания или слова. (16 баллов)**

Улыма

Син үзең китт(...), ә утырткан чәчәкләр(...) биредә калды. Алар ничек шәп үсә. Мин чәчәкләр(...) карый(...) да, улым Каприда бик яхшы нәрсәләр – чәчәкләр калдырып китте (...), эчемнән шатлана(...). Әгәр менә шулай һәрвакыт (...) һәр җирдә бөтен гомер(...) буена кешеләр өчен тик яхшы нәрсәләр – чәчәкләр, әйбәт фикерләр, үз(...) турында яхшы истәлекләр калдыра барса(...), синең бөтен тормыш(...) матур (...) күңелле бул(...). Шул вакыт син үзеңне кешеләргә кирәкле итеп сизәрсең һәм шуны тою сине яңа эшләргә рухландыр(). Дөньяда кеше(...) алуга караганда, аңа бир(...) күңеллерәк, ул (М.Горький).

**VI. Гади җөмләгә характеристика бирегез. – Дайте полную характеристику простому предложению. (4 балла)**

*Йомшак ябалак карлы кышкы кичләр, озын төннәр әнә шундый уйлар эчендә үтте* (М. Мәһдиев).

*Исправления не допускаются!*

**Межрегиональная предметная олимпиада Казанского федерального университета**
**по предмету «Татарский язык»**
**2012-2013 учебный год**
**10 класс**

**Шифр_____ Итоговой балл ___ ________**подпись предс. жюри

**I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез. – Найдите в каждом тесте один правильный ответ. (25 баллов)**

1. Татар теленең үз сүзләрендә күзәтелә торган иҗек калыплары саны (Количество типов слогов в татарском языке).

1) 8; 2) 7; 3) 6; 4) 5.

2. “Ирен-ирен, өрелмәле, сонор, авыз авазы” билгеләмәсенә туры килгән аваз (Губно-губной, щелевой, сонорный звук)

1) о; 2) м; 3) w; 4) в.

3. Ирен гармониясенә буйсынмаган сүзләрдән генә торган төркемне билгеләгез (Укажите ряд слов, состоящих из слов, в которых не наблюдается гармония гласных по рядам)

1) көндез, кичкырын, тотынып; 2) түрдә, бормалы, туганкай; 3) көмеш, иркен, тормышчан; 4) борынгы, корылма, чуртан.

4. “Графика” терминына бирелгән дөрес билгеләмәне күрсәтегез (Укажите правильное определение термина “графика»)

1) график тамгалар системасы ярдәмендә аралашу чарасы; 2) нинди дә булса телнең язу чаралары системасы; 3) авазларны язуда белдерү өчен хезмәт итә торган график тамга; 4) дөрес билгеләмә китерелмәгән.

5. Акустик яктан бары тавыштан гына торучы, иҗек төзи ала торган авазлар (Звуки, состоящие в акустическом плане только из голоса и способные образовать слог) -

1) сонор авазлар; 2) яңгырау тартыклар; 3) сузык авазлар; 4) саңгырау тартыклар.

6. Кара әле, **Айтуган**,
Кеп-кечкенә **ай туган** (Ә.Исхак) җөмләсендәге билгеләнгән сүзләр (Выделенные в предложении слова) –

1) омофоннар; 2) омографлар; 3) омоформалар; 4) саф лексик омонимнар.

7. Тарихи сүзләрдән торган сүзләр төркемен күрсәтегез (Укажите группу слов, состоящих только из историзмов)

1) алпавыт, чабата, чулпы, коммуна; 2) шура, угыл, сәгадәт, утар; 3) бармага, язмак, килмеш, сөйләмеш; 4) еглау, тулуг, угыл, үлтер.

8. “Түбәсе күккә тию” фразеологизмының мәгънәсе (Значение фразеологизма) –

1) кычкырып көлү; 2) шатлану; 3) елмаю; 4) сикереп тору.

9. Антонимнар бирелгән рәтне билгеләргә (Укажите ряд со словами-антонимами)

1) туу, дөньяга килү; 2) азатлык, бәйсезлек; 3) авызга су кабу, күп сөйләү; 4) йөгерү, чабу.

10. Сүзлекләр төзү белән шөгыльләнгән галимнәрнең фамилияләре кергән рәтне билгеләгез (Укажите ряд, где нашли место фамилии ученых-лексикографов)

1) М.Зәкиев, К.Зиннәтуллина, С.Ибраһимов; 2) К.Насыйри, Ф.Ганиев, Ф.Сафиуллина; 3) Г.Ибраһимов, Ф.Әмирхан, Ә.Еники; 4) Һ.Такташ, Ф.Кәрим, Г.Кутуй.

11. **Атлыларныкыдыр** сүзе ничә мәгънәле кисәктән тора? (Сколько морфем в указанном слове?)

1) 5; 2) 6; 3) 7; 4) 8.

12. Ясагыч кушымча ярдәмендә формалаша алмый торган сүз төркемен күрсәтегез (Укажите часть речи в татарском языке, которая не может быть образована при помощи словообразовательного аффикса)

1) рәвеш; 2) сыйфат; 3) сан; 4) дөрес җавап юк.

13. Тамырдаш сүзләр ул (Однокоренные слова это) –

1) тамырлары белән генә аерыла торган уртак мәгънәле сүзләр; 2) бер тамырдан булган сүзләр; 3) мәгънәләре бер үк булган сүзләр; 4) капма-каршы мәгънәле сүзләр.

14. Тамыр нигезле сүзне билгеләгез (Укажите слово с непроизводной основой)

1) кешелекле; 2) кешелеклегә; 3) кешегә; 4) кешелеклелек.

15. Мөнәсәбәт белдерүче модальлек кушымчалары гына тупланган төркемне билгеләгез (Укажите группу аффиксов, состоящих только из аффиксов модальности)

1) -лы/-ле, -лар/-ләр, -ак/-әк; 2) -у/-ү, -ып/-еп, -ны/-не; 3) -гач/-гәч, -кай/-кәй, -сыз/-сез; 4) -ды/-де, -ма/-мә, -тыр/-тер.

16. Билгеләү һәм сорау алмашлыклары кушылмасыннан торган алмашлыкның төркемчәсе – (Разряд сложных местоимений, образованных из определительных и вопросительных местоимений)

1) билгеләү алмашлыгы; 2) юклык алмашлыгы; 3) билгесезлек алмашлыгы; 4) күрсәтү алмашлыгы.

17. *Өйдә **келт** иткән тавыш та юк* (Г.Гыйльманов) җөмләсендә билгеләнгән сүз кайсы сүз төркеменә керә? (К какой части речи относится выделенное слово?)

1) кисәкчә; 2) аваз ияртеме; 3) ымлык; 4) хәбәрлек сүз.

18. *Һәркемгә билгеле: сәламәтлек – тормышның яме, чибәрлекнең нигезе* (Ш.Сайкин) җөмләсендә исем сүз төркеменә кергән сүзләр ( Сколько в предложении имен существительных?) –

1) 4; 2) 5; 3) 6; 4) 7.

19. ***Уйламыйча*** *эшләрсең – беләгеңне тешләрсең* мәкалендә билгеләнгән сүз (К какому разряду глагола относится выделенное слово?)

1) хәл фигыльнең беренче төре; 2) хәл фигыльнең икенче төре; 3) хәзерге заман хикәя фигыль; 4) хәзерге заман сыйфат фигыль.

20. ***Бар*** *янында* ***бар*** *яхшы, май янында бал яхшы* мәкалендә билгеләнгән сүзләр (К какой части речи относятся выделенные слова?) –

1) исемнәр; 2) боерык фигыльләр; 3) хәбәрлек сүзләр; 4) алмашлыклар.

21. Җөмләләр арасыннан 4 сүзтезмәсе булганын билгеләгез ( Укажите предложение, в котором имеется 4 словосочетания).

1) Мин акрын гына урман эченнән атлыйм (М.Мәһдиев); 2) Агач төпләрендә өелеп яткан чикләвекләрне кемнәр җыяр? (М.Мәһдиев); 3) Иртәнге чык тамчылары энҗе кебек ялтырый (Г.Хәсәнов); 4) Алтын балыкларның һәркайсы үзенчә матур (Г.Насрый).

22. Бирелгән җөмләнең төрен күрсәтегез (Укажите вид данного предложения)

*Миннән сиңа теләк шул: ил мактарлык үрнәк бул* (К.Нәҗми)

1) катнаш кушма җөмлә; 2) тиңдәш иярүле күп иярченле кушма җөмлә; 3) тиңдәш түгел иярүле күп иярченле кушма җөмлә; 4) бер-бер артлы иярүле күп иярченле кушма җөмлә.

23. Иясе исемләшмәгән сүз төркеме белән белдерелгән мәкальне билгеләгез (Укажите пословицу, подлежащее которого выражено не субстантивированной частью речи)

1) Җәяүле атлыга юл бирер;

2) Икәү көрәшсә, берәү егылыр;

3) Күп уйнаган бер елар;

4) Вактан эре җыела.

24. *Минем күңел шушы бик сирәк очрый торган бәхетне өмет итә* (М.Маликова) җөмләсендә ничә аергыч бар? (Сколько определений в предложении?)

1) 2; 2) 3; 3) 4; 4) 5.

25. *Үзең дә сизмәстән, күңелең түрендә җанга рәхәт өстәүче тылсымлы җыр тугандай була* (М.Хәсәнов) җөмләсендәге иярчен җөмләнең мәгънә ягыннан төрен билгеләгез. (Определите вид придаточного предложения в сложноподчиненном предложении)

1) иярчен күләм җөмлә; 2) иярчен рәвеш җөмлә; 3) иярчен вакыт җөмлә; 4) иярчен сәбәп җөмлә.

**II. Хикәядән соң булган тест биремнәрен үтәгез. – Выполните тестовые задания, приведенные после рассказа. (За каждый правильный ответ 1 балл = 25 балл)**

Салават күпере

1) Эссе, бөркү көннең ахырында болытлар куерып китте, һәм яңгыр коя башлады. 2) Яңгыр туктагач, горизонт өстендә батып бара торган кояш ялтырап күренде. 3) Нәкъ шул вакытта узып баручы кара болыт астында салават күпере калыкты. 4) Сизелер-сизелмәс кенә бер-берсенә күчә барган җиде саф төс: кызыл, кызгылт-сары, сары, яшел, күк, зәңгәр, миләүшә төсләр.

5) Нәрсә соң ул салават күпере? 6) Мондый могҗиза һавада ничек барлыкка килә?

7) Моның сәбәбе — кояш яктысы. 8) Ул ак кебек күренә. 9) Әмма чынлыкта җиде төрле төстән тора.

10) Кояш нурлары һава аркылы үткәндә, без аларны ак яктылык итеп күрәбез. 11) Ләкин менә аларның юлында яңгыр тамчысы очрый. 12) Кояш нуры тамчы аркылы үткәндә, яктылыкны тәшкил итүче төрле төстәге нурлар төрле почмаклар тәшкил итеп авышалар. 13) Кызыл төс нурлары — азрак, миләүшә төс нурлары барыннан да күбрәк авыша. 14) Ак нур составы өлешләргә таркала, һәм күктә салават күпере барлыкка килә. *(«Кем ул? Нәрсә ул?» китабы)*

1. Икенче җемләдәге ***өстендә*** сүзе сүз төркемнәренең кайсы группасына керә? (К какой группе частей речи относится выделенное слово?)

1) мөстәкыйль; 2) бәйләгеч; 3) модаль; 4) берсенә дә керми.

2. Төс исеме кызлар исеме буларак та кулланыла торган сүз кергән җөмлә - (Укажите номера предложений, в которых имеется название цвета, употребляющееся и как имя девочки)

1) 4, 13; 2) 5, 12; 3) 5, 10; 4) 10, 14.

3. 1-4 нче җөмләләрдән аергычлар саны 10 га тулган җөмләнең номерын билгеләгез (Из 1-4-х предложений укажите номер предложения, в котором имеется 10 определений)

1) 1; 2) 2; 3) 3; 4) 4.

4. 12-14 нче җөмләләр арасыннан чагыштыру дәрәҗәсендәге рәвешләр булган җөмләне билгеләгез (Укажите предложение с наречиями в сравнительной степени в 11-14 предложениях)

1) 11; 2) 12; 3) 13; 4) 14.

5. Тексттан рус теле аша кергән алынма сүзләре булган 2 җөмләнең номерларын күрсәтегез (Укажите номера 2-х предложений, в которых имеются заимствованные через русский язык слова)

1) 3, 12; 2) 2, 14; 3) 4, 13; 4) 9, 11.

6. Тексттагы тезмә кушма җөмләләр санын билгеләгез (обозначьте количество сложносочиненных предложений в тексте)

1) 2; 2) 3; 3) 4; 4) 5.

7. Тексттагы иярченле кушма җөмләләр санын билгеләгез (Обозначьте количество сложноподчиненных предложений)

1) 1; 2) 2; 3) 3; 4) 4.

8. 1-4 нче җөмләләрдән әйтелеше белән язылышы туры килмәгән 5 сүзе булган җөмләнең номерын күрсәтегез (Из указанных предложений обозначьте номер предложения, в котором имеется 5 слов, написание которых не соответствует произношению)

1) 1; 2) 2; 3) 3; 4) 4.

9. 2, 3, 7, 8 нче җөмләләр арасыннан хәреф саны белән аваз саны туры килмәгән 2 сүзе булган җөмләнең номерын билгеләгез (Из 2, 3, 7, 8 предложений укажите номер предложения, в котором в двух словах не совпадают количество звуков и букв)

1) 2; 2) 3; 3) 7; 4) 8.

10. 6 нчы җөмләдәге **могҗиза** сүзенең дөрес тәрҗемәсен билгеләгез (Укажите правильный перевод выделенного слова)

1) явление; 2) луч; 3) чудо; 4) облако.

11. 5 нче һәм 6 нчы җөмләләрдә берәр тезмә сүз бар. Аларны русчага бер сүз белән тәрҗемә итеп языгыз (В 5 и 6 предложениях есть по одному составному слову. Переведите их на русский язык одним словом).

_____________ ______________

12. Синоним сыйфатлар булган җөмләнең номерын билгеләгез (Укажите номер предложения, в котором имеются имена прилагательные-синонимы).

1) 1; 2) 4; 3) 9; 4) 12.

13. 10-13 нче җөмләләр арасыннан ясагыч кушымча ярдәмендә ясалган исемнәр бердән артык булган җөмләне күрсәтегез (Из 10-13 предложений укажите номер предложения, в котором есть больше одного имени существительного, образованного при помощи словообразовательного аффикса)

1) 10; 2) 11; 3) 12; 4) 13.

14. 1-6 нчы җөмләләрдән сингармонизмның рәт гармониясенә буйсынмаган сүзләр булган җөмләләрнең номерларын билгеләгез (Из указанных предложений найдите предложения, в которых не наблюдается гармония гласных по рядам)

1) 1, 4; 2) 3, 5; 4) 2, 6; 4) 4, 6.

15. 3-6 нчы җөмләләр арасыннан бер составлы исем җөмләнең номерын күрсәтегез (Из 3-6 предложений укажите номер односоставного именного предложения)

1) 3; 2) 4; 3) 5; 4) 6.

16. 5-8 нче җөмләләр арасыннан хәбәре исем белән белдерелгән җөмләнең номерын билгеләгез (Из указанных предложений найдите предложение, сказуемое которого выражено именем существительным)

1) 5; 2) 6; 3) 7; 4) 8.

17. Текстта ничә билгеле үткән заман хикәя фигыль бар? (Сколько в тексте глаголов определенного прошедшего времени?)

1) 3; 2) 4; 3) 5; 4) 6.

18. 5-9 нчы җөмләләрдән авазлар чиратлашу күренеше күзәтелгән сүзе булган җөмләне билгеләгез (Из указанных предложений найдите предложение, в котором имеется слово с чередованием согласных)

1) 5; 2) 6; 3) 7; 4) 8.

19. *Нәрсә **соң** ул салават күпере*? Җөмләсендә билгеләнгән сүз кайсы сүз төркеменә керә (К какой части речи относится выделенное в предложении слово?)

1) рәвеш; 2) кисәкчә; 3) бәйлек; 4) теркәгеч.

20. Татар телендә ике нокта белән билгеләнә торган тыныш билгесе куелуның 4 очрагын санагыз. Текстта шуларга мисаллар булса, шул җөмләләрнең номерын күрсәтегез, булмаганына үз мисалыгызны язып куегыз (Перечислите 4 случая употребления двоеточия в татарском языке. Если в тексте есть примеры, укажите номер предложения, если нет – напишите свои предложения).

**III. Нокталар урынына тиешле сүзләр өстәп языгыз. – Вставьте вместо точек нужные слова. (20 баллов)**

1. Сузык авазга тәмамланган иҗек _______________ иҗек дип атала.
2. Әйтелешне язуда тулысынча күрсәтү өчен хезмәт итә торган махсус язу системасы ______________________дип атала.
3. Тамыр һәм ясагыч кушымчадан торган сүзләр _____________ нигезле сүзләр дип йөртеләләр.

4. Сүзнең мәгънәсен лексик яки грамматик яктан үзгәртә торган мәгънәле кисәк (морфема) ________________ дип атала.

5. Берәр телдән башка телләргә кергән сүзләр _______________сүз дип аталалар.

6. Тел гыйлеменең сүзлекләр һәм аларны төзү мәсьәләләрен өйрәнә торган тармагы ____________________ дип атала.

7. Мәгънәләре, грамматик билгеләре һәм җөмләдә кулланылышлары буенча бер төркемгә берләшкән сүзләр ________________ дип атала.

8. Хикәя фигыльнең эшнең сөйләм моментыннан соң булачагын белдерә торган бер төре _______________________ хикәя фигыль дип атала.

9. Баш кисәкләргә яки үзара бер-берсенә буйсынып килгән кисәкләр ___________________________ дип атала.

10. Баш җөмләләре үзара тезү юлы белән бәйләнеп, составында бер генә булса да иярчен җөмләсе булган катлаулы кушма җөмлә _____________ кушма җөмлә дип атала.

**IV. Биремнәрне үтәгез. – Выполните задания. (10 баллов)**

*Сәнифә өйгә кайтып кергәндә, өйгә тәмле ис таралган, балалар, мәктәптән кайтып, өсләрен алыштырган, йөгерә-йөгерә өстәл әзерлиләр иде. (Э.Шәрифуллина)*

1. Тыныш билгеләренә номерлар куеп, аңлатыгыз (поставьте номера и объясните знаки препинания). (2 балл)
2. Схемасын сызып, төрен языгыз (определите тип предложения, начертите схему). (2 балл)
3. *Йөгерә* сүзенә фонетик анализ ясагыз. (1 балл)
4. *Өсләрен* сүзенең төзелешен, ясалышын аңлатма биреп тикшерегез. Шартлы билгеләр белән дә күрсәтегез (2 балл)
5. *Кергәндә, тәмле, мәктәптән* сүзләренә морфологик анализ ясагыз. (3 балл)

**V. Хикәядәге буш урыннарга кирәкле кушымчаларны языгыз. - Вставьте вместо пробелов нужные окончания. (16 баллов)**

**Дуслык**

… Яп-якты ишек төбе_ _ _ шулкадәр таныш, кадерле бер җан иясе утыра. Ул бик тә, бик тә Булат_ _ _ Куяны_ _ _ охшаган! Шул, шул! Куян! Әнә, колагындагы китек урын шул ук! Күзләре дә яратып, өзелеп төшәрдәй булып карап торалар...

Булат бераз вакыт өннән төшкә күчәргә куркыбрак торды да, тәвәккәлләп бусага_ _ _ атлап чык_ _ _. Шунда гына Куян авызы_ _ _ сөяк саплы пәкене шәйләп алды. Һәм... аңлады: төш түгел бу, өн бу, өн...

Менә бит хикмәт ни_ _ _!? Куян бу юлы да Булатның камышлык буенда төшер_ _ _ калдыр_ _ _ пәкесе_ табып китергән! Шул гына!

Булат уйлап та бетер_ _ _ алмады, Куян иплән кенә килеп авызы_ _ _ пәкене хуҗасының аяк очы_ _ _ куйды, аннары, минем эш_ _ _ бетте, китәргәме, юкмы, дигән кыяфәт чыгарып бер читкә барып утырды.

Булат, ниһаять, төше_ _ _ өненә кайтып җитте, атылып барып эт_ _ _ кочаклап алды. Моңа кадәр үзенең кирәклегенә шикләнеб_ _ _ утырган Куянга шул гына кирәк булган ахры. Ул койрыгын сикертеп торып басты, Булатның кулларын, битләрен тәмләп-тәмләп яла_ _ _ кереште.

Галимҗан Гыйльмановтан

**VI. Җөмлә кисәкләренең астына сызыгыз; гади җөмләгә характеристика бирегез. – Подчеркните члены предложения, дайте полную характеристику простому предложению. (4 балла)**

*Урман ягыннан борынга бөре исе, язгы дымлы туфрак исе килеп бәрелә. (М.Хәбибуллин)*

*Исправления не допускаются!*

**Межрегиональная предметная олимпиада Казанского федерального университета**
**по предмету «Татарский язык»**
**2012-2013 учебный год**
**11 класс**

**Шифр_____ Итоговой балл ___ ________**подпись председателя жюри

**I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез. – Найдите в каждом тесте один правильный ответ. (25 баллов)**

1. Иренләшкән сузыклар гына булган рәтне билгеләгез.
   1) а, ә; 2) ы, е; 3) и, ү; 4) Дөрес җавап бирелмәгән.
2. Түбән күтәрелешле сузыкларны билгеләгез.
   1) о, ө; 2) а, ә; 3) у, ү; 4) и, ы.
3. Чагыштырмача кыска сузыклар гына булган рәтне билгеләгез.
   1) ы, е; 2) а, ә; 3) у, ү; 4) и, ы.
4. Чагыштырмача озын сузыклар гына булган рәтне билгеләгез.
   1) а, о; 2) и, ы; 3) у, ә; 4) ө, ү.
5. *По̲чта, вы̲шка, э̲кран* сүзләрендә билгеләнгән сузыкларның әйтелеш үзенчәлеген белдергән җавапны күрсәтегез.
   1. Бераз таррак итеп әйтелә. 2. Бераз киңрәк итеп әйтелә. 3. Төрлечә итеп әйтелә. 4. Бераз сузыбрак, киңрәк итеп әйтелә.
6. Омофоннар гына булган рәтне билгеләгез.
   1. Ис керү – искерү; ат алу – аталу. 2. А`ерма – аерм`а; б`үлмә - бүлм`ә. 3. Суга – суга; атларга – атларга. 4. Дөрес җавап бирелмәгән.
7. Метонимиягә мисал бирелгән җөмләне билгеләгез.
   1. Дәү әнием алтын сүз әйтте. 2. Университет шимбә өмәсенә чыккан. 3. Әлфия – сыйныф җитәкчесенең уң кулы. 4. Су буенда бөдрә таллар үсә.
8. Тарихи сүзләрдән генә торган рәтне билгеләгез.
   1. Гасыр, атна, угълан. 2. Чабата, мәдрәсә, коллектив. 3. Алпавыт, чулпы, өяз. 4. Председатель, радио, электр.
9. Күчерелмә мәгънәле сүзләр булган рәтне билгеләгез.
   1. Ак бәхет; җыр сибү. 2. Өстәл ясау; кыяр үстерү. 3. Апа сүзе; малай тырышлыгы. 4. Көрәк сабы; исемлектә бишенче.
10. Фразеологик әйтелмәләрдән генә торган рәтне күрсәтегез.
    1. Хәзинә табу; уртак тел табу. 2. Таш күпер; күккә күтәрелү. 3. Йөрәк ялкыны; бака туе. 4. Сыбызгы сызгырту; базарга бару.
11. Тамырдаш сүзләр бирелгән рәтне күрсәтегез.
    1. Талчыга, талсыз, таллык. 2. Юату, югыч, юан. 3. Сынык, сынучан, сыныксыз. 4. Көлле, көләч, көлсез.
12. Ясагыч кушымча белән ясалган сүзләр рәтен билгеләгез.
    1. Бәрәңге, көзгегә, җирләр. 2. Чират, чирәм, читкә. 3. Укытучы, укучы, язучы. 4. Табышмак, тапкыр, табышлы.
13. Сүзләр кушылу ысулы белән ясалмаган сүзләр рәтен күрсәтегез.
    1. Ассызыклау, искиткеч. 2. Күпкырлы, очсыз-кырыйсыз. 3. Саубуллашу, искитмәү. 4. Дөрес җавап бирелмәгән.
14. Нигезе дөрес билгеләнгән сүзләр рәтен табыгыз.
    1. Киенмә-гән, укыт-са. 2. Җырлаш-каннар, языл-сын. 3. Сөйлә-гәч, тырыш-ып. 4. Бүл-мәдә, иш-кәктән.
15. Ясалу ысуллары иң аз булган сүз төркемен табыгыз.
    1. Фигыльләр. 2. Исемнәр. 3. Сыйфатлар. 4. Рәвешләр.
16. Мөстәкыйль сүз төркемнәре генә булган рәтне билгеләгез.
    1. Шалтыр-шолтыр, һәркем, сирәк. 2. Белмәгән, кебек, чөнки. 3. Сүзчән, ләбаса, сау бул. 4. Берөзлексез, язгы, ләкин.
17. Төшем килешендәге исемнәр генә булган рәтне күрсәтегез.
    1. Кышын, язын. 2. Китабын, ялын. 3. Җәен, кичтән. 4. Иртән, киемен.
18. Сыйфатлар гына булган рәтне билгеләгез.
    1. Ерак, күп. 2. Нинди, кайсы. 3. Тиктормас, күтәренке. 4. Бөтен, якын.
19. Рәвешләр генә булган рәтне билгеләгез.
    1. Атлап, атналап. 2. Килгәләп, айлап. 3. Яшьләй, төлкедәй. 4. Кайтып, укыгач.
20. Төшем юнәлешендәге фигыльләр генә булган рәтне күрсәтегез.
    1. Киенгән (кеше), укылган (китап). 2. Сөйләнгән (доклад), җырланган (җыр). 3. Узылган (юл), сөйләшкән (сүз). 4. Ябылган (түбә), көткән (эш).

21. Предмет яки төшенчәләрне атаучы кисәкне ачыклап, аларның билгесен, санын яки кемгә һәм нәрсәгә каравын белдерә -

1. Ия. 2. Тәмамлык. 3. Аергыч. 4. Хәл.

22. Эш-хәрәкәтне белдергән кисәкне ачыклый, аның объектын, үтәүчесен белдерә -

1. Хәбәр. 2. Аергыч. 3. Хәл. 4. Тәмамлык.

23. *Буяучыга да кереп чыгасым бар (К.Нәҗми)* җөмләсенә дөрес бирелгән аңлатманы табыгыз.

1. Билгеле үтәүчеле бер составлы фигыль җөмлә.2. Билгесез үтәүчеле бер составлы фигыль җөмлә. 3. Гомуми үтәүчеле бер составлы фигыль җөмлә. 4. Дөрес җавап бирелмәгән.

24. Йортыгыз зурмы? – *Кечкенә (Т.Гыйззәт)* – билгеләнгән җөмләгә дөрес аңлатманы табыгыз.

1. Иясез җөмлә. 2. Билгеле үтәүчеле бер составлы фигыль җөмлә. 3. Билгесез үтәүчеле бер составлы фигыль җөмлә. 4. Ким җөмлә.

25. Аерымланган аныклагычлар янында

1. Ике төрле; 2. Өч төрле; 3. Дүрт төрле; 4. Биш төрле тыныш билгесе куела.

**II. Хикәя буенча тест биремнәрен үтәгез. – Выполните тестовые задания по рассказу. (За каждый правильный ответ 1 балл = 20+5 = 25 баллов)**

Челтер чишмә

1) Авылда туып-үсеп, читтә яшәгән кеше һәрвакыт туган җирен искә төшерә. 2) Куш учлап тәмле суын эчкән, бала чактан ук күңеленә моңлы җыры белән кереп урнашкан таныш чишмәсен күз алдына китерә. 3) Аны туган җиренә челтерәп аккан шушы чишмәләр тарта.

4) Һәр авылның үз чишмәсе бар. 5) Кешеләр чишмәләргә матур-матур исемнәр биргәннәр. 6) Туган як чишмәсе магнит кебек ераклардан үзенә тартып тора. 7) Кайда гына йөрмә, суының тәме авызда саклана, җыры әкрен генә күңел түрендә сызыла.

8) Авылымның баш чишмәсе башкаларга охшамаган. 9) Сөзәк тау асты тигез җиргә әверелгән, шуннан кыр башланган җирдә тибә ул.10) Суы вак ташлар арасыннан түбәнгә йөгерә, икенче бер чишмәгә кушыла. 11) Авыл турысыннан үткәнче, инешкә башка чишмәләр дә кушыла.

12) Баш чишмәнең мул сулы булып акканын да, корырга җыенган чакларын да яхшы хәтерлим. 13) Хәзер кешеләр чишмәгә яңа юл ачтылар. 14) Чишмә башын бурап, җир астыннан торба салып, суын авылга китерделәр – игелекле эш эшләделәр. 15) Бу җәйдә кайтуымда да чишмә янына бардым, шифалы суын эчтем, моңын тыңладым. 16) Моңы – бала чакта ишеткән җыр, ә җырында кешеләргә җиткерәсе сөенеч авазлары ишетелә сыман. *(К.Тәхау.)*

1. Ирен гармониясе күзәтелгән сүзләр генә булган рәтне билгеләгез.

1) Авылда, чишмәсе. 2) Моңлы, йөгерә. 3) Суы, кайтуымда. 4) Җәйдә, эчтем.

2. Сингармонизмга буйсынмаган сүзләрне күрсәтегез.

1) Корырга, ишетелә. 2) Шифалы, магнит. 3) Астыннан кешеләргә. 4) Дөрес җавап бирелмәгән.

3. Кече тел ассимиляциясе күзәтелгән сүзләрне билгеләгез.

1) Җыенган, башланган. 2) Тыңладым, хәтерлим. 3) Акканын, янына. 4) Икенче һәм өченче җаваплар дөрес.

4. Кайсы җөмләдәге сүзләрдә үз хәрефе булмаган авазлар юк?

1) Аны туган җиренә челтерәп аккан шушы чишмәләр тарта. 2) Һәр авылның үз чишмәсе бар. 3) Кешеләр чишмәләргә матур-матур исемнәр биргәннәр. 4) Туган як чишмәсе магнит кебек ераклардан үзенә тартып тора.

5. Кайсы җөмләдә ике бәйләгеч кушымчасы булган сүз юк?

1) Авылымның баш чишмәсе башкаларга охшамаган. 2) Сөзәк тау асты тигез җиргә әверелгән, шуннан кыр башланган җирдә тибә ул. 3) Суы вак ташлар арасыннан түбәнгә йөгерә, икенче бер чишмәгә кушыла. 4) Авыл турысыннан үткәнче, инешкә башка чишмәләр дә кушыла.

6. Күчерелмә мәгънәдәге сүз булган рәтне билгеләгез.

1) Чишмәләр тарта. 2) Туган җиренә. 3) Челтерәп аккан чишмәләр. 4) Шушы чишмәләр.

7. Йөкләтү юнәлешендәге фигыль булган җөмләне күрсәтегез.

1) Баш чишмәнең мул сулы булып акканын да, корырга җыенган чакларын да яхшы хәтерлим. 2) Хәзер кешеләр чишмәгә яңа юл ачтылар. 3) Чишмә башын бурап, җир астыннан торба салып, суын авылга китерделәр – игелекле эш эшләделәр. 4) Бу җәйдә кайтуымда да чишмә янына бардым, шифалы суын эчтем, моңын тыңладым.

8. Кайсы җөмләдә исемләшкән рәвеш бар?

1) Һәр авылның үз чишмәсе бар. 2) Кешеләр чишмәләргә матур-матур исемнәр биргәннәр. 3) Туган як чишмәсе магнит кебек ераклардан үзенә тартып тора. 4) Кайда гына йөрмә, суының тәме авызда саклана, җыры әкрен генә күңел түрендә сызыла.

9. Тамыр+ясагыч кушымча+модальлек кушымчасы+модальлек кушымчасы схемасына туры килгән сүз булган рәтне билгеләгез.

1) Тигез җиргә әверелгән. 2) Шуннан кыр башланган.3) Ташлар арасыннан. 4) Чишмәгә кушыла.

10. Тамыр+ясагыч кушымча+модальлек кушымчасы+бәйләгеч кушымча схемасына туры килгән сүз булган рәтне билгеләгез.

1) Баш чишмәнең акканын. 2) Корырга җыенган чакларын. 3) Яхшы хәтерлим. 4) Дөрес җавап бирелмәгән.

11. Кайсы җөмләдә затланышсыз фигыльләр юк?

1) Авылда туып-үсеп, читтә яшәгән кеше һәрвакыт туган җирен искә төшерә. 2) Куш учлап тәмле суын эчкән, бала чактан ук күңеленә моңлы җыры белән кереп урнашкан таныш чишмәсен күз алдына китерә. 3) Кайда гына йөрмә, суының тәме авызда саклана, җыры әкрен генә күңел түрендә сызыла. 4) Баш чишмәнең мул сулы булып акканын да, корырга җыенган чакларын да яхшы хәтерлим.

12. Аерымланган рәвеш хәле булган җөмләне күрсәтегез.

1) Баш чишмәнең мул сулы булып акканын да, корырга җыенган чакларын да яхшы хәтерлим. 2) Хәзер кешеләр чишмәгә яңа юл ачтылар. 3) Чишмә башын бурап, җир астыннан торба салып, суын авылга китерделәр – игелекле эш эшләделәр. 4) Бу җәйдә кайтуымда да чишмә янына бардым, шифалы суын эчтем, моңын тыңладым.

13. Бәйлек сүзләр булмаган җөмләне табыгыз.

1) Суы вак ташлар арасыннан түбәнгә йөгерә, икенче бер чишмәгә кушыла. 2) Авыл турысыннан үткәнче, инешкә башка чишмәләр дә кушыла. 3) Бу җәйдә кайтуымда да чишмә янына бардым, шифалы суын эчтем, моңын тыңладым. 4) Дөрес җавап юк

14. Катнаш кушма җөмләне күрсәтегез.

1) Кайда гына йөрмә, суының тәме авызда саклана, җыры әкрен генә күңел түрендә сызыла. 2) Суы вак ташлар арасыннан түбәнгә йөгерә, икенче бер чишмәгә кушыла. 3) Авыл турысыннан үткәнче, инешкә башка чишмәләр дә кушыла. 4) Моңы – бала чакта ишеткән җыр, ә җырында кешеләргә җиткерәсе сөенеч авазлары ишетелә сыман.

15. Бирелгән җөмләгә дөрес билгеләмәне табыгыз.

*Сөзәк тау асты тигез җиргә әверелгән, шуннан кыр башланган җирдә тибә ул.*

1) Тиңдәш кисәкләр белән катлауландырылган гади җөмлә. 2) Теркәгечсез тезмә кушма җөмлә җөмлә. 3) Иярченле кушма җөмлә. 4) Катнаш кушма җөмлә.

16. Кайсы җөмләдә асыл сыйфат рәвеш хәле булып килгән?

1) Суы вак ташлар арасыннан түбәнгә йөгерә, икенче бер чишмәгә кушыла. 2) Авыл турысыннан үткәнче, инешкә башка чишмәләр дә кушыла. 3) Баш чишмәнең мул сулы булып акканын да, корырга җыенган чакларын да яхшы хәтерлим. 4) Хәзер кешеләр чишмәгә яңа юл ачтылар.

17. Кайсы җөмләдә аергыч булып килгән өч асыл сыйфат бар?

1) Авылда туып-үсеп, читтә яшәгән кеше һәрвакыт туган җирен искә төшерә. 2) Куш учлап тәмле суын эчкән, бала чактан ук күңеленә моңлы җыры белән кереп урнашкан таныш чишмәсен күз алдына китерә. 3) Аны туган җиренә челтерәп аккан шушы чишмәләр тарта. 4) Дөрес җавап бирелмәгән.

18. Кире сүз тәртибе (инверсия) кайсы җмләдә күзәтелә?

1) Авылымның баш чишмәсе башкаларга охшамаган. 2) Сөзәк тау асты тигез җиргә әверелгән, шуннан кыр башланган җирдә тибә ул. 3) Суы вак ташлар арасыннан түбәнгә йөгерә, икенче бер чишмәгә кушыла. 4) Авыл турысыннан үткәнче, инешкә башка чишмәләр дә кушыла.

19. Бирелгән җөмләдә сызык куюга дөрес аңлатманы табыгыз.

*Моңы – бала чакта ишеткән җыр, ә җырында кешеләргә җиткерәсе сөенеч авазлары ишетелә сыман.*

1) Гомумиләштерүче сүз алдыннан куелган. 2) Аныкланмыш белән аныклагыч исем белән белдерелгән. 3) Баш кисәкләре алмашлыклар белән белдерелгән. 4) Баш кисәкләре исемнәр белән белдерелгән.

20. Кайсы җөмләдә үткән заман сыйфат фигыль туры тәмамлык булып килгән?

1) Баш чишмәнең мул сулы булып акканын да, корырга җыенган чакларын да яхшы хәтерлим. 2) Хәзер кешеләр чишмәгә яңа юл ачтылар. 3) Чишмә башын бурап, җир астыннан торба салып, суын авылга китерделәр – игелекле эш эшләделәр. 4) Бу җәйдә кайтуымда да чишмә янына бардым, шифалы суын эчтем, моңын тыңладым.

21. Татар телендә өтер куюның 5 очрагын санагыз. Текстта шуларга мисал булса, шул җөмләнең номерын языгыз, булмаганына үз мисалыгызны язып куегыз. (Перечислите 5 случаев постановки запятых в татарском языке. Если в тексте есть примеры, укажите номер предложения, если нет – напишите свои предложения. **(5 баллов)**

**III. Нокталар урынына тиешле сүзләр өстәп языгыз. – Вставьте вместо точек нужные слова. (За правильный ответ по каждому правилу по 2 балла = 20 баллов)**

1. [а], [ә] - ... күтәрелешле сузыклар.
2. [ж], [ң], [һ], [w] - … теленә генә хас булган тартыклар.
3. Татар телендә сингармононизмның ... һәм ... гармонияләре күзәтелә.
4. Килеп чыгышы ягыннан татар телендә ... сүзләр бик күп кулланыла.
5. Кулланылу өлкәсе ягыннан татар телендә ... һәм ... сүзләр бар.
6. Кулланылу ешлыгы (дәрәҗәсе) ягыннан татар телендә ... һәм .. сүзләр бар.
7. Морфемика сүзләрнең ... кисәкләрен өйрәнә.

8. Сыйфатлар ... һәм ... дигән төркемчәләргә бүленә.
9. Барлык-юклыкта һәм төрле юнәлешләрдә ... фигыль төркемчәләре дә килә ала.
10. Бәйлекләр белән теркәгечләр ... сүз төркемнәре дип атала.

**IV. Биремнәрне үтәгез. – Выполните задания. (10 баллов)**

*Март кояшы шулкадәр юмарт якты ак бүген Нәкыя эшләрен тәмамлап өйгә кайтып җиткәнче күзләре дә юньләп ачыла алмады* (И.Низ.)

1. Тыныш билгеләрен куеп, аңлатыгыз (поставьте и объясните знаки препинания). **(2 балла)**
2. Схемасын сызып, төрен языгыз (определите тип предложения, начертите схему). **(2 балла)**
3. *Юньләп* сүзенә фонетик анализ ясагыз. **(1 балл)**
4. *Дөнья* сүзенә лексик анализ ясагыз. **(1 балл)**
5. *Тәмамлап* сүзенең төзелешен, ясалышын аңлатма биреп (тамгалар белән генә түгел) тикшерегез. **(1 балл)**
6. *Эшләрен, кайтып җиткәнче, дә* сүзләренә морфологик анализ ясагыз. **(3 балла)**

**V. Хикәядәге нокталар урынына кирәкле хәрефләрне яки кушымчаларны языгыз. - Вставьте вместо точек нужные буквы или окончания. (16 баллов)**

Тамчылар

Кар өст...нә энҗе тамчылар тама. Алар төн...н барлыкка килгән боз сөңг...ләр оч...ннан тамалар. Аларның үз көйләре, үз моңнары бар.

Алар тавышы... ишетеп, таллар да йокылары... уянды. Уяндылар да март күге... карадылар. Талның ак песиләре... кояш баешыннан искән җилләр сыйпый.

Тамчылар, бергә җыел..., елга... таба юл яра. Алар җыры... ишетеп, бәбкә үләне дә кар асты... бор...н төртә башлады. Тиздән урман юллары... тамчылардан күлләвекләр җәелер, умырзая көнгә багар, гөрләвекләр инешләргә йөг...ргәндә, күкебашлар ак каеннар тирәсе... бизәрләр. *(Вакытлы матбугаттан)*

**VI. Җөмлә кисәкләренең астына сызыгыз; гади җөмләгә характеристика бирегез. – Подчеркните члены предложения, дайте полную характеристику простому предложению. (4 балла)**

*Йөзлекәй карчык, кулларын каш өстенә куеп, баеп баручы кояшка, Зәй буеның яшел әрәмәләрен алсу төскә манган шәфәкъ нурына озак кына карап торды, кичке салкынча һава белән болын буйларыннан, басулардан кайткан үлән исен, өлгереп килүче игеннәрнең салат ипие исен, борын канатларын киереп иснәде.* (Г.А.)

**Ответы заданий**
**межрегиональной олимпиады школьников 9 класса по татарскому языку**
**2012/2013 учебный год**
**9 нчы класс**

| **I. Тестларга җаваплар** | **II.Текст тестларына җаваплар** | **III.Нокталар урынына тиешле сүзләр** | **IV. Җөмлә буенча биремнәр** |
|---|---|---|---|
| 1-ә<br>2-б<br>3-б<br>4-ә<br>5-ә<br>6-а<br>7-ә<br>8-в<br>9-в<br>10-в<br>11-а<br>12-б<br>13-ә<br>14-ә<br>15-а<br>16-б<br>17-а<br>18-ә<br>19-а<br>20-а<br>21-б<br>22-а<br>23-в<br>24-ә<br>25-а | 1-ә<br>2-а<br>3-в<br>4-ә<br>5-ә<br>6-б<br>7-ә<br>8-ә<br>9-в<br>10-в<br>11-в<br>12-ә<br>13-б<br>14-а<br>15-б<br>16-а<br>17-а<br>18-в<br>19-б<br><br>20 - №8 - Санау интонациясе белән үзара бәйләнгән тиңдәш кисәкләр арасына (бу очракта тиңдәш хәбәрләр арасына) **өтер** куела; №9 - Санау интонациясе ярдәмендә бәйләнешкә кергән гади җөмләләр арасына **өтер** куела; №11 - Кереш сүзләр җөмлә башында килгәндә, алардан соң **өтер** куела | 1. Сүзтезмә.<br>2. Кушымча.<br>3. Җөмлә кисәге.<br>4. Калька.<br>5. Кереш сүзләр.<br>6. Тиңдәш аергычлар.<br>7. Гомумиләштерүче сүзләр.<br>8. Тезмә кушма җөмлә.<br>9. Эндәш сүз.<br>10. Аналитик иярчен җөмлә. | 1. **(2) мин дә илкәемә кайтып китәрмен әле** – баш җөмлә, **1) Ком сахрасында ыгы-зыгы басылгач** – иярчен җөмлә. Иярчен җөмлә төзелеше ягыннан синтетик, мәгънәсе ягыннан вакыт җөмлә. Иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйләүче чара - **-гач** хәл фигыль формасы.<br>Бу – иярченле кушма җөмлә.<br>2. **Ком сахрасында ыгы-зыгы басылгач, мин дә илкәемә кайтып китәрмен әле** (Т.Әйди).<br>Компонентлар арасына өтер куела, чөнки синтетик иярчен җөмлә баш җөмләдәге үзе ияреп килгән сүздән ераклашкан.<br>3. **Басылгач** - фигыль, затланышсыз, III төр хәл фигыль, барлыкта, зат-сан белән төрләнми, төшем юнәлешендә; җөмләдә хәбәр булып килә.<br>4. **Илкәемә** - ил - тамыр, **-кәй** - модальлек кушымчасы (исемнәрдә иркәләү кушымчасын белдерә), **- ем** - бәйләгеч кушымча (1 нче зат берлектә тартым кушымчасы), **- ә** - бәйләгеч кушымча (ю.к. кушымчасы); тамыр нигез; ил-кәй, баба-кай, дус-кай.<br>**5. Ыгы-зыгы** – тынычсызлык, тәртипсезлек, чуалыш, шау-шулы (хәрәкәт), арлы-бирле (йөреш), ашыгып, кабаланып (йөрү), ыгы-зыгылы (тормыш), шау-шу, шау-гөр килү. |

**V.** Улыма

Син үзең китт**ең**, ә утырткан чәчәкләр**ең** бирелә калды. Алар ничек шәп үсә. Мин чәчәкләр**гә** карыйм да, улым Каприда бик яхшы нәрсәләр – чәчәкләр калдырып китте **дип**, эчемнән шатлана**м**. Әгәр менә шулай һәрвакыт **һәм** һәр җирдә бөтен гомер**ең** буена кешеләр өчен тик яхшы нәрсәләр – чәчәкләр, әйбәт фикерләр, үз**ең** турында яхшы истәлекләр калдыра барса**ң**, синең бөтен тормыш**ың** матур **һәм** күңелле бул**ыр**. Шул вакыт син үзеңне кешеләргә кирәкле итеп сизәрсең һәм шуны тою сине яңа эшләргә рухландыр**ыр**. Дөньяда кеше**дән** алуга караганда, аңа бир**ү** күңеллерәк, ул (М.Горький).

**VI.** Бу – гади, тулы, җәенке, ике составлы, тиңдәш кисәкләр белән катлауландырылган, сүз тәртибе уңай булган, раслау, хикәя җөмлә.

**Ответы заданий**
**межрегиональной олимпиады школьников 10 класса по татарскому языку**
**2012/2013 учебный год**
**10 нчы класс**

| **I. Тестларга җаваплар** | **II.Текст тестларына җаваплар** | **III.Нокталар урынына тиешле сүзләр** | **IV. Җөмлә буенча биремнәр** |
|---|---|---|---|
| 1-3<br>2-3<br>3-2<br>4-2<br>5-3<br>6-1<br>7-1<br>8-2<br>9-3<br>10-2<br>11-1<br>12-3<br>13-2<br>14-3<br>15-4<br>16-1<br>17-2<br>18-2<br>19-1<br>20-3<br>21-2<br>22-4<br>23-2<br>24-2<br>25-2 | 1-2<br>2-1<br>3-3<br>4-3<br>5-2<br>6-2<br>7-3<br>8-2<br>9-3<br>10-3<br>11-радуга, возникает<br>12-1<br>13-3<br>14-3<br>15-2<br>16-3<br>17-2<br>18-7<br>19-2<br><br>20 - Татар телендә 2 нокта белән билгеләнә торган тыныш билгесе:<br>1. Тиңдәш кисәкләр алдында килгән гомумиләштеркүче сүздән соң;<br>2. Аналитик иярчен кушма җөмләдә көттерү паузасы дигән бәйләүче чараны белдерү өчен;<br>3. Фигыль белән белдерелгән ачыкланмышны ачыклап килгән аныклагыч алдыннан;<br>4. Туры сөйләмле җөмләдә автор сөйләменнән соң. (4 балл)<br>Тексттагы 4 нче җөмләдә тиңдәш кисәкләр алдында куелган. (1 балл)<br>Әгәр үз җөмләсе булса, 1 балл. | 1. Ачык.<br>2. Транскрипция.<br>3. Ясалма.<br>4. Кушымча.<br>5. Алынма.<br>6. Лексикография.<br>7. Сүз төркемнәре.<br>8. Киләчәк заман.<br>9. Иярчен кисәкләр.<br>10. Катнаш. | 1) 1 нче өтер – синтетик иярчен җөмләдән соң;<br>2 нче өтер – тезү юлы белән бәйләнгән баш җөмләләр арасында.<br>3,4 нче өтерләр – аерымланган хәлне аерган.<br>5 нче өтер – тиңдәш хәбәрләр арасында.<br>Нокта – җөмлә ахыры.<br><br>2) Бу катнаш кушма җөмлә |

**V.** Дуслык

… Яп-якты ишек төбе**ндә** шулкадәр таныш, кадерле бер җан иясе утыра. Ул бик тә, бик тә Булат**ның** Куяны**на** охшаган! Шул, шул! Куян! Әнә, колагындагы китек урын шул ук! Күзләре дә яратып, өзелеп төшәрдәй булып карап торалар...

Булат бераз вакыт өннән төшкә күчәргә куркыбрак торды да, тәвәккәлләп бусага**дан** атлап чык**ты**. Шунда гына Куян авызы**ндагы** сөяк саплы пәкене шәйләп алды. Һәм... аңлады: төш түгел бу, өн бу, өн...

Менә бит хикмәт ни**дә**!? Куян бу юлы да Булатның камышлык буенда төшер**еп** калдыр**ган** пәкесе**н** табып китергән! Шул гына!

Булат уйлап та бетер**ә** алмады, Куян иплән кенә килеп авызы**ндагы** пәкене хуҗасының аяк очы**на** куйды, аннары, минем эш**ем** бетте, китәргәме, юкмы, дигән кыяфәт чыгарып, бер читкә барып утырды.

Булат, ниһаять, төше**ннән** өненә кайтып җитте, атылып барып этен кочаклап алды. Моңа кадәр үзенең кирәклегенә шикләнеб**рәк** утырган Куянга шул гына кирәк булган ахры. Ул койрыгын сикертеп торып басты, Булатның кулларын, битләрен тәмләп-тәмләп яла**рга** кереште.

**VI.** Бу гади, тулы, җәенке, ике составлы, тиңдәш ияләр белән катлауланырылган сүз тәртибе уңай булган раслау, хикәя җөмлә.

**Ответы заданий**

**межрегиональной олимпиады школьников 11 класса по татарскому языку**
**2012/2013 учебный год**
**11 нче класс**

| **I. Тестларга җаваплар** | **II.Текст тестларына җаваплар** | **III.Нокталар урынына тиешле сүзләр** | **IV. Җөмлә буенча биремнәр** |
|---|---|---|---|
| 1-4<br>2-2<br>3-1<br>4-3<br>5-4<br>6-1<br>7-2<br>8-3<br>9-1<br>10-3<br>11-3<br>12-4<br>13-4<br>14-3<br>15-1<br>16-1<br>17-2<br>18-3<br>19-3<br>20-2<br>21-3<br>22-4<br>23-1<br>24-4<br>25-3 | 1-2<br>2-2<br>3-1<br>4-3<br>5-2<br>6-1<br>7-3<br>8-3<br>9-2<br>10-3<br>11-3<br>12-3<br>13-4<br>14-1<br>15-2<br>16-3<br>17-2<br>18-2<br>19-4<br>20-1<br>21-аерымл. хәл. №№ 1, 14;<br>тиңд. кис. №№ 2,7,12;<br>иярч. җөмлә ахыры № 3;<br>җөмлә ар-да тезүле бәйл. №16.<br>**Өстәмәләр:** эндәш сүз яки кереш сүздә соң. | 1. Түбән.<br>2. Татар.<br>3. Ирен, рәт.<br>4. Алынма.<br>5. Һөнәри, диалек-таль.<br>6. Актив. Пассив.<br>7. Мәгънәле.<br>8. Асыл, нисби.<br>9. Барлык.<br>10. Бәйләгеч. | **Өтерләр**: № 1, 2 – тиңдәш хәбәрләр арасына;<br>№ 3 – баш җөмләдән соң;<br>№ 4, 5 – аерымл. рәвеш хәлләре;<br>№ 6 – иярчен җөмл. арасында;<br>**Нокта** – хикәя җөмлә ахыры. |

**V.** Тамчылар

Кар өст**е**нә энҗе тамчылар тама. Алар төн**е**н барлыкка килгән боз сөңг**е**ләр оч**ы**ннан тамалар. Аларның үз көйләре, үз моңнары бар.

Алар тавышы**н** ишетеп, таллар да йокылары**ннан** уянды. Уяндылар да март күге**нә** карадылар. Талның ак песиләре**н** кояш баешыннан искән җилләр сыйпый.

Тамчылар, бергә җыел**ып**, елга**га** таба юл яра. Алар җыры**н** ишетеп, бәбкә үләне дә кар асты**ннан** бор**ы**н төртә башлады. Тиздән урман юллары**на** тамчылардан күлләвекләр җәелер, умырзая көнгә багар, гөрләвекләр инешләргә йөг**е**ргәндә, күкебашлар ак каеннар тирәсе**н** бизәрләр. *(Вакытлы матбугаттан)*

**VI.** Бу – гади, тулы, җәенке, ике составлы, аерымланган рәвеш хәлләре һәм тиңдәш кисәкләр белән катлауландырылган, сүз тәртибе уңай булган, раслау, хикәя җөмлә.